СОВЕТ РАИФСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РАИФА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19.12.2025г.** с.Бело-Безводное **№ 20**

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 10 сентябрендәге 180 номерлы Раифа авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Раифа авыл җирлеге советы карар кылды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 10 сентябрендәге 180 номерлы Раифа авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 6 пунктчасында «күпфатирлы йорт проектлана торган, тәгалләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар физик затлар мөлкәтенә салым буенча чираттагы салым (исәп-хисап) чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган рәсми басылып чыккан көннән соң бер ай узгач үз көченә керә..

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Раифа авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Раифа авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе

И.Г. Нуриев